БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» 12 2023 ел № 335

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә өстәмә түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм тарифлар билгеләү тәртибе һәм бәясе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Мәгариф өлкәсендә халыкның ихтыяҗларын һәрьяклап канәгатьләндерү, хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту, хезмәтләрне үстерүне һәм камилләштерүне тәэмин итү, өстәмә финанс чараларын җәлеп итү, матди-техник базаны киңәйтү максатларында, халыкка социаль хезмәт күрсәтү кагыйдәләре нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы карары, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68–ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 5 июнендәге 2556/14 номерлы « Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) мәгариф оешмалары тарафыннан физик (юридик) затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында Регламентны раслау хакында» боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә өстәмә түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм тарифлар билгеләү тәртибе һәм бәясе турындагы нигезләмәне 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф учреждениеләре күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары һәм «Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2023елның «25» 12
335 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар билгеләү тәртибе турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар билгеләү тәртибе турында нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы карары, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 6 июнендәге 2556/14 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) мәгариф оешмалары тарафыннан физик (юридик) затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында Регламентны раслау хакында» боерыгы нигезендә эшләнгән һәм ул Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм тарифлар билгеләү тәртибен җайга сала(алга таба –Учреждение)

1.2.Учреждениеләр закон нигезендә түләүле хезмәтләр күрсәтә, шул исәптән түләүле белем бирү хезмәтләре (алга таба - түләүле хезмәтләр). Түләүле хезмәтләр халыкның мәгариф өлкәсендәге ихтыяҗларын һәрьяклап канәгатьләндерү, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең матди-техник базасын киңәйтү максатында күрсәтелә.

1.3.Әлеге Нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:
- башкаручы - Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мәгариф учреждениеләре;
- кулланучы - килешү нигезендә үзе яисә башка затлар өчен түләүле белем бирү хезмәтләренә заказ бирү нияте булган физик яисә юридик зат;
- башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль

законы, Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләре билгеләгән мәгънәләрдә кулланыла.

1.4.Түләүле хезмәтләр аларны алучының ризалыгы белән генә күрсәтелә ала. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алучының баш тартуы аңа бирелә торган төп хезмәтләр күләме кимүгә сәбәп була алмый.

1.5.Түләүле хезмәтләр күрсәтү Учреждение бушлай күрсәтергә тиешле төп хезмәтләр күрсәтү сыйфатына зыян китерә алмый яки аның сыйфатына начар тәэсир итә алмый.

1.6.Түләүле хезмәтләр мәгариф учреждениеләре бинасында күрсәтелә.

## 2.Түләүле хезмәтләр турында мәгълүмат

2.1. Түләүле хезмәтләр балаларның иҗади сәләтләрен булдыруга һәм үстерүгә, аларның интеллектуаль, әхлакый һәм физик камиллеккә индивидуаль ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә, сәламәт һәм имин яшәү рәвеше культурасын формалаштыруга, сәламәтлеген ныгытуга, шулай ук аларның буш вакытын оештыруга юнәлдерелгән. Түләүле хезмәтләр аларның җәмгыятьтәге тормышка яраклашуын, шулай ук күренекле сәләтләрен күрсәткән балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итүне тәэмин итә.

2.2. Кулланучыларның сорауларын һәм тиешле мөмкинлекләрне исәпкә алып, Учреждение башка түләүле хезмәтләр дә күрсәтә ала, мәсәлән, оештыру хезмәтләре:

- ата-аналарның психологик-педагогик тәэмин ителеше;
- балаларның мәнфәгатьләрен һәм теләктәшлеген исәпкә алып, төрле эшчәнлек төрләре буенча ата-аналар белән берлектә түгәрәкләр, студияләр, клуб эше;
- бәйрәмнәр һәм күңел ачу, ял итү оештыру.

2.3. Түләүле хезмәтләргә төп белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда, аларны төркемнәргә бүлү, Учреждениенең статусы нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру; факультатив, индивидуаль һәм төркемле дәресләр, төп гомуми белем бирү программаларында бирелгән сәгатьләр исәбеннән сайлау курслары керми.

Бу максатларга кулланучылар акчаларын җәлеп итү рөхсәт ителми.

2.4. Түләү алу түбәндәгеләр өчен рөхсәт ителми:

- академик бурычны бетерү;
- мәгариф учреждениеләренең төп эшчәнлегенә караган контроль эшләрне, зачетларны, имтиханнарны, лаборатор, гамәли эшләрне төрле үзгәртеп корулар;
- Учреждениегә укырга керү, бер Учреждениедән икенчесенә күчерү, бер белем бирү программасыннан икенчесенә, бер формадан икенчесенә күчү;
- Учреждениенең китапханәсеннән һәм башка мәгълүмат фондларыннан уку планында каралган барлык дисциплиналарны уңышлы үзләштерү өчен кирәкле Учреждениедән файдалану;
- балаларның (аларның ата-аналарының яисә законлы вәкилләренен) теләкләрен исәпкә алмыйча түләүле хезмәтләр күрсәтү.

2.5. Түләүле хезмәтләрнең конкрет исемлеге, аларны бирү тәртибе Учреждение Уставы белән билгеләнә.

## 3.Түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм шартнамәләр төзү тәртибе

3.1. Түләүле хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген алып бару өчен Учреждениегә түбәндәгеләр кирәк:

- хезмәт күрсәтүләрдә ихтыяҗны өйрәнергә һәм кулланучыларның күздә тотылган контингентын билгеләргә;
- сәламәтлекне саклау һәм иминлек кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә түләүле хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар тудыру;
- Уставта планлаштырыла торган түләүле хезмәтләр исемлеген һәм аларны бирү тәртибен беркетү;
- Учреждениенең кайда булуы турында белешмәләр, эш режимы, түләүле хезмәтләр исемлеген үз эченә алган бушлай, һәркем ала алырлык һәм дөрес мәгълүмат белән, аларның бәясе, хезмәт күрсәтү шартлары, ташламалары турында белешмәләрне кертеп, аерым категория кулланучылар өчен, тулаем алганда смета белән һәм бер алучыга исәпләгәндә урнаштырырга хокуклы булган ташламалар турындагы белешмәләрне кертеп, кулланучыларны тәэмин итәргә;
- түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм шартларын регламентлаучы норматив актлар белән кулланучыларны таныштырырга;
- түләүле хезмәтләр күрсәтүгә керемнәр һәм чыгымнар сметасын исәпләп чыгарырга. Керемнәрнең һәм чыгымнарның сметасы әлеге учреждениедә гамәлгә ашырыла торган хезмәтләр комплексы буенча исәпләнергә мөмкин;
- кадрлар составын тәэмин итәргә һәм шартнамәләр төзергә. Түләүле хезмәтләр күрсәтү эшләрен башкару өчен Учреждениенең төп хезмәткәрләре дә, башка оешмалар белгечләре дә, шартнамә нигезендә җәлеп ителергә мөмкин;
- Учреждениядә түләүле хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Учреждение җитәкчесенең боерыгын чыгарырга.

Расларга:

- Учреждениедә түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында нигезләмә;
- түләүле белем бирү хезмәтләренең һәр төренә белем бирү программалары;
- уку, календарь-тематик план;
- түгәрәкләр, секцияләр расписаниесе, белгечнең эш графигы;
- хезмәтләрне кулланучылар белән шартнамәнең якынча формасын;
- эшләрне кабул итү турындагы актның якынча формасын һ.б.

Түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен билгели торган кирәкле документларны эшләгәндә Учреждение башка шартларда түләүле хезмәт күрсәтеләчәк гражданнарның ташламаларын һәм (яисә) ташламалы категорияләрен билгеләргә мөмкин.

3.2.Учреждение килешү төзегәнче һәм аның гамәлдә булу чорында кулланучыга үзе турында һәм түләүле хезмәтләр турында, аларның дөрес сайлау мөмкинлеген тәэмин итә торган дөрес мәгълүмат бирә.

3.3.Учреждение «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законында һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда каралган тәртиптә һәм күләмдә түләүле хезмәтләр күрсәтү турында белешмәләр булган кулланучыга җиткерергә тиеш.

3.4.Әлеге нигезләмә, шул исәптән һәр белем бирү программасы буенча укыту бәясен раслау турындагы документ, белем бирү эшчәнлеген оештыруның һәм гамәлгә ашыруның төп мәсьәләләре буенча локаль норматив актлар, шулай ук «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон таләпләре нигезендә башка мәгълүмат Интернет челтәрендәге рәсми сайтта Учреждение тарафыннан ачык кулланылышта урнаштырыла. Учреждение «Интернет» челтәрендәге учреждениенең рәсми сайтында булган документларның мәгълүматын аларга тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән алып ун эш көне эчендә яңартуны тәэмин итә.

3.5.Түләүле хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә ике нөсхәдә төзелә, аларның берсе -башкаручы, икенчесе - кулланучылар өчен.

3.6.Килешүдә күрсәтелгән белешмәләр башкаручының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шартнамә төзелгән датага урнаштырылган мәгълүматка туры килергә тиеш.

3.7.Кулланучыга килешү төзү өчен түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк: Кулланучының паспорты, белем алучы яисә тәрбияләнүченең туу турында таныклык (яисә паспорты), сайланган өстәмә белем бирү профиле буенча шөгыльләнү өчен балада каршылыклар булмавы турында медицина белешмәсенең төп нөсхәсе, килешү төзелгән көнгә кадәр өч айдан да артык булмаган вакытта бирелгән бүтән белешмәләр, күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрнең үзенчәлеге белән бәйле башка белешмәләр.

3.8.Түләүле хезмәтләр күрсәткәндә Учреждениенең билгеләнгән режимы саклана.

3.9.Учреждение хезмәткәрләренә түләүле хезмәтләр күрсәтү төп эшеннән буш вакытта башкарыла.

3.10.Башкаручы кулланучы түләүле хезмәт күрсәтүне сораган очракта килешү төзергә тиеш һәм, законда һәм башка норматив хокукый актларда каралган очраклардан тыш, шартнамә төзүгә карата бер заказчыга өстенлек бирергә хокуклы түгел.

3.11.Заказ бирүче тарафыннан шартнамә төзү өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшырмау түләүле хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә төзүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

## 4.Түләүле хезмәтләр бәясен билгеләү буенча төп нигезләмәләр

4.1. Түләүле хезмәт күрсәтүләрнең бәясен исәпләү өчен, учреждение чыгымнары турыдан-туры һәм читләтеп башкарыла.

4.2. хезмәт күрсәтү белән турыдан-туры бәйләнгән һәм аны күрсәтү процессында кулланыла торган чыгымнар турыдан-туры чыгымнарга керә:

- хезмәт хакы;

- Россия Федерациясе салым законнары нигезендә бердәм социаль салым түләү чыгымнарын, шулай ук производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү тарифлары буенча кертемнәрне кертеп, хезмәт өчен түләүгә карата түләүләр;

- түләүле хезмәт күрсәтү барышында кулланыла торган материалларга һәм башка ресурсларга чыгымнар;

- түләүле хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган төп чараларны амортизацияләү.

4.3. Турыдан-туры булмаган чыгымнарга учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган чыгымнар керә, әмма турыдан-туры түләүле хезмәт күрсәтү процессында таләп ителми:

- идарәче персоналның хезмәт хакы;

- идарәче персоналның хезмәт хакына карата түләүләр;

- хуҗалык чыгымнары (агымдагы хуҗалык максатлары өчен материал һәм предметларга чыгымнар, канцелярия товарлары, транспорт, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен инвентарь һәм түләү, элемтә хезмәтләре, җиһазларны һәм инвентарьларны, биналарны һәм корылмаларны агымдагы ремонтлау);

командировкаларга һәм хезмәт разъездларына чыгымнар;

- хезмәтләр күрсәтүгә турыдан-туры бәйле булмаган биналарны, корылмаларны һәм башка төп чараларны амортизацияләү;

- башка чыгымнар.

Санап үтелгән турыдан-туры булмаган чыгымнар хезмәт күрсәтүләр бәясенә исәп-хисап коэффициентлары аша карый.

4.4. Түләүле хезмәтләрнең рентабельлек дәрәҗәсе хезмәт күрсәтүләр базарында шундый ук хезмәт күрсәтүләрнең бәясен бәяләү нәтиҗәләре буенча бюджет учреждениесе тарафыннан билгеләнә.

## 5. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән акчалар алу һәм аларны тоту тәртибе

5.1. Түләүле хезмәт бәясе Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен түләүне билгеләү тәртибен раслау турында» 2012 елның 16 мартындагы 184 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гражданнар һәм юридик затлар өчен карары нигезендә билгеләнә.

5.2. Түләүле хезмәтләр күрсәтүгә керемнәр һәм чыгымнар сметасы турыдан-туры Учреждение тарафыннан эшләнә.

5.3. Учреждение тарафыннан түләүле хезмәтләргә тарифлар гамәлгә куючы тарафыннан раслана һәм һәр уку елы башына яңадан каралырга мөмкин.

5.4. Башкаручы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр өчен түләү кулланучы тарафыннан ай саен килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокта башкарыла.

5.5. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акча Учреждениенең бюджеттан тыш счетында туплана. Түләүле хезмәтләр күрсәткән өчен акча җыю рөхсәт ителми.

5.6. Учреждение түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчаларны, керемнәр һәм чыгымнар сметасы нигезендә түбәндәгеләр өчен тота:

- хезмәткәрләргә хезмәт хакы - 75%;
- коммуналь хезмәтләр өчен түләү - 7 %;
- башка чыгымнар - 18%.

5.7. Учреждение түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны бюджет акчалары исәбеннән каплауга рөхсәт итәргә хокуклы түгел. Шулай ук күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күләме дә бюджет финанславын киметү өчен нигез булып тормый.

## 6. Якларның җаваплылыгы

6.1. Учреждение түләүле хезмәтләр күрсәткәндә Заказ бирүче алдында түбәндәгеләр өчен җаваплы:

- йөкләмәләрне тулы күләмдә үтәмәгән өчен (шартнамәдә күрсәтелгән уку программасын гамәлгә ашыру буенча һәм сәгатьләр саны буенча) һәм Учреждение тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәдә күрсәтелгән сыйфат өчен;
- шартнамәдә күрсәтелгән срокларда белем бирү программасын үтәмәгән өчен;
- Учреждениядә түләүле хезмәтләр күрсәткән вакытта балаларның тормышы һәм сәламәтлеге өчен;
- белем бирү процессын оештырганда куркынычсыз шартлар өчен;
- Учреждение укучыларының, тәрбияләнүчеләрнең һәм хезмәткәрләренең хокуклары һәм ирекләре бозылган өчен;
- Россия Федерациясе законнарында каралган башка гамәлләр өчен.

6.2. Заказ бирүче алдында җаваплылыктан тыш, Учреждение түбәндәгеләр өчен җаваплы:

- финанс чараларының максатчан тотылмавы;

хезмәтне саклау таләпләрен үтәмәү.

6.3. Түләүле хезмәтләр күрсәткәндә Учреждение эшчәнлеге өчен шәхси җаваплылыкны Учреждение җитәкчесе башкара.

6.4. Кулланучы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

## 7. Түләүле хезмәтләр күрсәтүнең тәртибен һәм сыйфатын тикшереп тору

7.1. Түләүле хезмәтләрне оештыру буенча законнарның үтәлешен "Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе (алга таба - Мәгариф идарәсе) тикшереп тора.

7.2. Мәгариф идарәсе, әгәр бу эшчәнлек төп эшчәнлеккә зыян китерсә, Түләүле хезмәтләр күрсәтү буенча Учреждение эшчәнлеген туктатырга хокуклы.

7.3. Түләүле хезмәтләр күрсәтү очраклары Учреждениенең төп эшчәнлегенә зыян китергәндә яисә бюджеттан финанслана торган хезмәтләр өчен түләүне алганда, гамәлгә куючы (Учредитель) законсыз алынган суммаларны тиешле бюджетка алу турында карар кабул итәргә хокуклы.

7.4. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне контрольдә тотуны тәэмин итү һәм финанс агымының үтә күренмәлелеген тәэмин итү өчен Учреждение Мәгариф бүлегенә хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 числосына кадәр тиешле хисап бирергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2023елның «25» 12
335 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә
өстәмә түләүле хезмәтләргә бәяләр прейскуранты

| № | Өстәмә хезмәт атамасы | 1 сәгать бәясе (сумнарда) | Айлык бәясе |
|---|---|---|---|
| 1 | Өстәмә белем бирү хезмәте | | |
| 2 | Өстәмә хезмәт | | |

Бәя яклар килешүе буенча, төзелгән килешү нигезендә билгеләнә.